ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлеге составына керүче Турай авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

« 22 » ноябрь 2024 ел № 5

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 22 ст., “Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе хакында нигезләмәне раслау турында” Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлеге Советының 2019 елның 4 октябрендәге 100 номерлы карары нигезендә, 2024 елның 22 ноябрендә 16.00 сәг. “2025 елда Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегенең Турай авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I төркем инвалидларны, Бөек Ватан сугышы тыл ветераннарын, югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендә укучы студентларны, Россия Армиясенә сроклы хезмәткә чакырылганнарны, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын түләүдән азат итеп, үзара салым акчаларын кертергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә Сез ризамы?” дигән сорау буенча узган гражданнар җыенында гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде.

1) Су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау ( Турай торак пунктына тирәннән су алу насосы сатып алу, Турай торак пунктындагы яңа су җыю башнясына санитар саклау зонасын киртәләү өчен материал сатып алу, яңа су җыю башнясына санитар саклау зонасын киртәләү)
2) торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү ( Турай торак пунктында үлән чабу өчен триммер сатып алу; МТЗ 82.1 тракторы өчен чапкыч сатып алу)
3) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту ( Турай торак пунктында кышкы чорда юлларны кардан чистарту, шартнамә буенча эшләр өчен түләү); юл өслеге өчен вак таш сатып алу ; транспорт хезмәтләре; МТЗ 82.1 тракторын карап тоту)

4) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (1 ( бер ) данә янгын сүндерү гидрантларын сатып алу, Турай торак пунктының Крайняя урамында 1(бер) данә янгын сүндерү гидрантларын урнаштыру.)
5) һәйкәлләрне төзекләндерү, ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) булмаган) һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү ( Турай авылында махсус хәрби операциядә һәм Әфганстан сугышында катнашучыларга һәйкәлләр кую)

Гражданнар җыены беркетмәсенә ярашлы, җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 300 граждан кертелгән, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны 198 кеше; тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: ”Риза” - 198 кеше, “каршы” – 0.

Бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегенең Турай торак пункты гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. Менделеевск муниципаль районының Турай авыл җирлегенең Турай торак пунктында гражданнар җыенын узган дип санарга, җыен нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

“2025 елда Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегенең Турай авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I төркем инвалидларны, Бөек Ватан сугышы тыл ветераннарын, югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендә укучы студентларны, Россия Армиясенә сроклы хезмәткә чакырылганнарны, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын түләүдән азат итеп, үзара салым акчаларын кертергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә Сез ризамы?” дигән сорау каралды һәм карар кабул ителде:

6) Су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау ( Турай торак пунктына тирәннән су алу насосы сатып алу, Турай торак пунктындагы яңа су җыю башнясына санитар саклау зонасын киртәләү өчен материал сатып алу, яңа су җыю башнясына санитар саклау зонасын киртәләү)
7) торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү ( Турай торак пунктында үлән чабу өчен триммер сатып алу; МТЗ 82.1 тракторы өчен чапкыч сатып алу)
8) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту ( Турай торак

пунктында кышкы чорда юлларны кардан чистарту, шартнамә буенча эшләр өчен түләү); юл өслеге өчен вак таш сатып алу ; транспорт хезмәтләре; МТЗ 82.1 тракторын карап тоту)

9) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (1 ( бер ) данә янгын сүндерү гидрантларын сатып алу, Турай торак пунктының Крайняя урамында 1(бер) данә янгын сүндерү гидрантларын урнаштыру.)

10) һәйкәлләрне төзекләндерү, ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) булмаган) һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү ( Турай авылында махсус хәрби операциядә һәм Әфганстанда катнашучыларга һәйкәлләр кую)

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталына http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru " Турай авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Менделеевск муниципаль районы
Турай авыл җирлеге башлыгы Г.Б. Куляшова